**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ**

422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОН СОВЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

15 сентябрь 2023 ел № 195

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Уставы нигезендә, 2023 елның 08 сентябрендә узган тыңлаулар беркетмәләрен һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Олы Әтнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турындагы 2023 елның 08 сентябрендәге бәяләмәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Советы **карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Олы Әтнә авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен яңа редакциядә расларга.
2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Олы Әтнә авыл җирлегенә территориаль планлаштыру федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында (https://fgistp.economy.gov.ru/) Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Олы Әтнә авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. “Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында”гы 26.05.2022 №125 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Советы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында (www.atnya.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (игълан итәргә).
5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Советының җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән үзара эшчәнлек, законлылык, хокук тәртибе һәм регламенты буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Әтнә муниципаль районы башлыгы-**
**Әтнә район Советы Рәисе** **Г.Г. Хәкимов**